РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«13» ноября 2024 ел Олы Кайбыч ав. № 290

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 18 октябрендәге 66 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 08 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 18 октябрендәге 66 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 60 пунктында «66 статьядагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьядагы 12 һәм 12_1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 нче кушымтаның 62 пунктында:

а) 3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителә алмый.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 5 абзац белән тулыландырырга:

«Күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозуларның билгеләре ачыкланса, мондый мөмкинлек федераль законда контроль рәвеше, Татарстан Республикасы законы турында мондый контроль рәвеше күрсәтелгән очракта «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1

пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул ителергә мөмкин.».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе О.Д. Макаровага йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин